**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ГЛАВА**
**Чубар-Абдулловского сельского поселения Азнакаевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул авыл җирлеге Советы**
**БАШЛЫГЫ**


ул. Советская, д. 81 , село Чубар-Абдуллово
Азнакаевского муниципального района,
423323
Тел. (факс) (85592)38-7-37
Chabd.Azn@tatar.ru

Совет урамы, 81, Чубар-Абдул авылы
Азнакай муниципаль районы, 4233237
Тел. (факс) (85592) 38-7-37
Chab.Azn@tatar.ru


**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«21» октябрь 2025года № 2

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул авыл җирлегенең Чубар-Абдул торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Чубар-Абдул авыл җирлеге Уставы нигезендә, карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул авыл җирлеге Чубар-Абдул авылында теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен 2025 елның 31 октябрендә 10 сәгать 00 минутта үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының билгеләргә;

2. Билгеләргә:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул авыл җирлеге Чубар-Абдул авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын оештыручы – Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул авыл җирлеге Башкарма комитеты;
- гражданнар җыенын уздыру вакыты-2025 елның 31 октябрендә 10.00 сәгатьтән 11.00 сәгатькә кадәр;
- гражданнар җыенын үткәрү урыны- Чубар-Абдул авылы, Совет урамы, 85 нче йорт, Чубар-Абдул авылы мәдәният Йорты залы;

3. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул авыл җирлеге Башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

- 2025 елның 21 октябреннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул авыл җирлеге Башкарма комитетында

гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын гражданнарга түбәндәге адрес буенча бирергә: Чубар-Абдул авылы, Совет урамы, 81 йорты;

- сайлау хокукына ия булган Чубар-Абдул торак пунктында яшәүчеләр исемлеген төзергә;

- гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләү;

-Чубар-Абдул торак пункты халкына массакүләм мәгълүмат чараларында һәм гражданнарның җыены турында башка ысуллар белән хәбәр итәргә.

4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2026 елда Чубар-Абдул авыл җирлеге Чубар-Абдул торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган,

- 1 төркем инвалидларыннан,

- көндезге уку формасында укучы студентлардан,

- махсус хәрби операциядә катнашучылар, аларның гаилә әгъзаларыннан

- Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт узучы гражданнардан тыш 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- ремонт, коймалар кору, традицион күмү урыннарын төзекләндерү (Чубар-Абдул авылы зиратын киртәләү өчен материал сатып алу)
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Совет, Чапаев, Яшьләр, Комсомол урамнары буенча юлларны грейдер белән тигезләү)
- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (Чубар-Абдул авылы юлларын һәм территорияләрен кардан чистарту)

« РИЗА» «КАРШЫ».

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы, Чубар-Абдул авылы, Совет ур., 85 йорт адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

5. Әлеге карар ул халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Башлык: Н. Ә. Фәтхетдинов